РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2023г. г. Альметьевск №104

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2019 елның 16 декабрендәге 182 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 26 номерлы, 2021 елның 17 июнендәге 36 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 69 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтаның «Район башкарма комитеты җитәкчесе» 3 бүлегендә:

1.1.1. 3.12 пунктының унсигезенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 3.12 пунктының егерменче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән соң) үз кечenә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов